**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
Балык бистэсе
муниципаль районы
Корноухово авыл жирлегенен
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422644, Корноухово,
Совхоз урамы, 3

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
Рыбно- Слободский
муниципальный район
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
Корноуховского сельского поселения
422644, Корноухово,
ул. Совхозная, 3

Тел.: (84361) 27205, факс: (84361) 27205, e-mail:Kuh.RS @tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.08.2025 №58

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл (шәһәр) җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 25 апрельдэге «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Корноухово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыны (урыннары) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» гы 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив актны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге «Җыйнау, туплау, куллану, зарарсызландыру, ташу (күчерү) һәм урнаштыру тиешенчә булмау гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында»гы 2314 номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл (шәһәр) Башкарма комитетының 2023 елның 25 апрельдэге «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Корноухово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыны (урыннары) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» гы 28 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны теркәлә торган яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге территориясендә кулланылышта булган терекөмешле лампаларны туплау урынының (урыннарының) урнашуы турында әйләнә-тирә мохит

торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтындагы «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарындагы мәгълүмат стендларында (стойкаларында) урнаштыру юлы белән.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: : Балык Бистәсе муниципаль районы, Корноухово авылы, Совхозная урамы,3 йорт,Шетнево –Чирмешэн авылы,Советская урамы 21 йорт,Зюзино авылы ,Центральная урамы 6 йорт,Наумово авылы,Наумово урамы 3 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Корноухово авыл җирлеге башлыгы: Г.С.Гумашян